Проект

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Ф.С. Габделганиевның (алга таба – Вәкаләтле вәкил) 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Вәкаләтле вәкилнең 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән эшенең системалы, шул исәптән судта яклауда катнашу һәм консультация рәвешендә хокукый ярдәм күрсәтү юлы белән, алып барылуын, шулай ук аның Татарстан Республикасында эшкуарлык үсеше өчен уңайлы шартлар булдыруда актив булышлык итүен билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына Вәкаләтле вәкилнең 2025 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүне һәм Вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Вәкаләтле вәкилгә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм эшкуарлар берләшмәләре белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасында эшкуарлык климатын яхшыртуга юнәлдерелгән эшне дәвам итүне.

4.2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, республика башкарма хакимият органнары һәм эшлекле ассоциацияләр белән берлектә салым законнарындагы үзгәрешләргә бәйле мәсьәләләр буенча кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен системалы нигездә агарту чаралары үткәрүне дәвам итүне.

4.3. Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында җәмәгатьчелек вәкилләре институты белән бергәләп, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, аерым дәүләт вәкаләте яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән башка органнар, оешмалар белән хезмәттәшлектә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мәнфәгатьләрен яклау һәм аларның законлы хокукларын торгызу буенча эшне дәвам итүне.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына республика башкарма хакимият органнары һәм Вәкаләтле вәкил белән берлектә Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлеге субъектларына дәүләт преференцияләре бирү өлешендә законнарны камилләштерү эшен дәвам итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе